КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 гыйнвар г.Казань № 31

2024 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2023 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында 22 128 831,5 мең сум күләмендә юл эшләре программасын;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 090 302,912 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Яр Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 281 279,858 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча 657 556,331 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән, 2 207 460,899 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының иң якын иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм

реконструкцияләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 1 095 856,8 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 257 052,9 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 2 426 907,2 мең сум күләмендә субсидия рәвешендә кергән акча һәм 569 274,6 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Транспорт системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты чаралары кысаларында дәүләт күләмендәге һәм хосусый партнерлык механизмын кулланып тормышка ашырыла, федераль бюджеттан 5 339 467,9 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 17 150 823,7 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләренә керү юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән 300 000,0 мең сум күләмендәге программаны.

2. 2024 елга Татарстан Республикасындагы гомуми файдаланудагы юлларда юл эшләренең гомуми суммасы 54 504 814,6 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең 2024 елга җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларда юл эшләренең муниципаль программаларын тормышка ашыруга кушымта нигезендә 1 549 954,6 мең сум күләмендә җибәрелә торган муниципаль юл фондлары ассигнованиеләре күләмнәре турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин